**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 19.03.2018 № 146-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 87-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы указы кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 87-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 3.4.3 пунктын өстәргә:

«3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.4.2 пунктында каралган мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә

хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.».

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә.Кузюров